# Татар теле дәресләрендә мәкальләр куллану

# МӘКАЛЬ ДИП НӘРСӘГӘ ӘЙТЕЛӘ?

1.Безгә кардәш төрки халыкларның кайберләре аны борынгылар сүзе, кайберләре — аталар сүзе, картлар сүзе дип атыйлар.

2."Мәкаль" сүзе безгә гарәпчәдән кергән. Аның мәгънәсе урынлы сүз яки тиешле урынында әйтелгән сүз була.



3. Мәкаль кыска һәм тирән мәгънәле булганга, аны халык хикмәте дип атау барлык халык фольклорында бик таралган.

**Белем беләккә** *наданлык хур,*

**Укусыз белем юк,** *көч бирә*

**Белем –нур,** *белемсез көч юк*

**Дөньяда иң зур байлык-** *белемнән*

*эзлә*

**Бәхетне юлдан эзләмә,** *белем*

# Сыйфат

Әдәпле бала гарьле була,
әдәпсез бала гарьсез була.
Иркә бала рәхәт күрмәс.
Татлы тел бәхет били.
Акылы кысканың- теле озын.

# Сан

Бишектәге бишкә төрләнә.

Алтыда белгән ана телең
алтмышта да онытылмас.

Йөз сум акчаң булганчы,
йөз дустың бусын.

# Боерык фигыль

Буй үстергәнче, акыл үстер.

Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да сөйләмә.

Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел.

# Рәвеш

- Алма агачыннан ерак китми.
- Аз сөйлә, күп эшлә.
- Чеметеп җыйсаң, учлап ашарсың.

# Иярченле кушма җөмлә

Бер ялган сөйләсәң,
тугыз дөресеңә дә ышанмаслар.

Кем эшләми, шул ашамый.

Башы беткән артыннан барыр,
юлы беткән юлыннан барыр.

Эше бар тик тормас, эшләмәгән көн күрмәс.

«Эш беткәч - уйнарга ярый». “Картаеп каткач буыннар эш белү уңайсыз ул”.

“Иң мөкаддәс нәрсә эш”.

“Эш агачы һәрвакыт та бик юмарт китерер җимеш”.

«Кояш һәм ай- ике туган агай – эне».

«Күктәге торна өчен, күп очырганнар кулында бар кошын».

«Акча барда бар да дус»,

«Акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр»

**Балаларны татар халык мәкальләре белән таныштырганда, дәрестә уен технологиясен куллану бик уңышлы.**

**Мәсәлән, хезмәт турында мәкальләр өйрәнгәндә түбәндәге биремне файдаланып була.**

Чарасы юк эш өчен кайгыруда мәгънә юк.
Чарасына керсәң, булмый торган эш юк.
Чеметеп җыйсаң, учлап ашарсың.





**Гали үз эшендә,
Вәли үз эшендә.
Гадел башлык –
халык өчен, залим
башлык – тамак
өчен.**

Кем эшләми, шул ашамый.
Кеше эшенә карап, тамак туймый.
Киңәшле эш таркалмас.
Кәсеп иткәнгә насыйп иткән.
Көн – эшләр өчен, төн – йоклар өчен.
Күмәк эш үрчемле булыр.
Күп эшләсәң эш көне, тук булырсың кыш көне.



Начар останың коралы үтми.
Нишлисең эш уңмагач, умач токмач булмагач!
Корал эшләр, кул мактаныр.



Син эшне сөйсәң, эш тә сине сөяр.
Сөйләп күрсәткәнче, эшләп күрсәт.
Сүз күп җирдә эш аз була.
Сүздә мактанма, эштә мактан.



Теленә салынган – эшенә абынган.
Телең белән дау куптарганчы, эшең белән тау куптар.
Тирләп эшләсәң, аш тәмле була.
Түшеңә карама, эшенә кара.









